КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 декабрь г.Казань № 1119

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2014 ел, 1 октябрь, 707 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2014 ел, 1 октябрь, 707 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 май, 401 нче; 2019 ел, 29 май, 451 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21. Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеге хезмәткәрләренең иң чик санын 2 кеше, вазыйфаи окладлар буенча айлык хезмәт өчен түләү фондын 7 560 АКШ доллары күләмендә билгеләргә.»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеге турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта «Россия Федерациясе һәм Кытай Халык Республикасы законнары» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары һәм Кытай Халык Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта «һәм гуманитар элемтәләрне һәм контактларны» сүзләрен «, гуманитар һәм башка элемтәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Вәкиллек үз компетенциясе чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыруга вәкаләт бирелгән орган йөкләмәләре нигезендә:»;

3.2 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Вәкиллек эшчәнлеген һәм аның мөлкәтен
финанс белән тәэмин итү

5.1. Вәкиллек эшчәнлеген финанс һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм законнарга каршы килми торган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла. Вәкиллек эшчәнлеген финанслау өчен акча Татарстан Республикасы бюджетында карала.

5.2. Вәкиллек мөлкәте Татарстан Республикасы милке булып тора һәм аңа оператив идарә хокукында беркетелә.

5.3. Вәкиллекнең структурасы һәм штат расписаниесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

6.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин